ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__6__» ____02___ 2020__ г. № 39

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл хуҗалыклары, оешма, предприятиеләре, учреждениеләре һәм муниципаль берәмлекләре (җирлекләре) арасында ТАССРның төзелүнең 100 еллыгына һәм Балтач районының 90 еллыгына багышланган район мәдәни-массакүләм һәм спорт чаралары үткәрү хакында

Талантлы, үзенчәлекле коллективларның иҗади мөмкинлекләрен эзләү һәм гамәлгә ашыру, традицион мәдәниятне саклау, районда мәдәният һәм сәнгатьне пропагандалау, шулай ук, халык арасында физик культураны һәм спортны пропагандалау, авыл хезмәтчәннәренең сәламәтлеген ныгыту өчен уңайлы шартлар тудыру максатыннан Балтач муниципаль районы башлыгы **КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елның февраленнән апрель аена кадәр Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында авыл хуҗалыклары, оешма-предприятиеләре , учреждениеләре һәм муниципаль берәмлекләре (җирлекләре) арасында ТАССР ның төзелүенә 100 ел һәм Балтач районының 90 ел тулуына багышланган район мәдәни -массакүләм һәм спорт чаралары уздырырга.

2. 1 нче кушымта нигезендә район бәйгеләренең эшче төркеме составын расларга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл хуҗалыклары, оешма- предприятиеләре, учреждениеләре һәм муниципаль берәмлекләре (җирлекләре) арасында ТАССР ның 100 еллыгына һәм Балтач районының 90 ел тулуына багышланган район мәдәни- массакүләм һәм спорт чаралары нигезләмәләрен №2 һәм №3 кушымталары нигезендә расларга;

4. Тәкъдим итү:

4.1 Авыл хуҗалыклары, оешма-предприятиеләре, учреждение һәм муниципаль берәмлек (җирлек) җитәкчеләренә район чараларын (транспорт, сәхнә костюмнары, декорация, музыка аппаратурасы һ. б.) әзерләүдә катнашырга.

4.2 «Татмедиа» ААҖ филиалы «Хезмәт» газетасы (Зәкиев в.М.) һәм «Кайтаваз» радиосы (Маннапова Г. с.) Балтач муниципаль районы авыл хуҗалыклары, оешма-предприятиеләре, учреждениеләре һәм муниципаль берәмлекләре (җирлекләре) арасында ТАССРның 100 еллыгына һәм Балтач

районының 90 ел тулуына багышланган район мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларын уздыру барышын яктыртырга.

4.3 Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасына (Ильясов Р.М.) Балтач муниципаль районы авыл хуҗалыклары, оешма -предприятиеләре, учреждениеләре һәм муниципаль берәмлекләре (җирлекләре) арасында ТАССР ның 100 еллыгына багышланган район мәдәни-массакүләм һәм спорт чаралары йомгакларын үткәрүгә киткән чыгымнарны, чираттагы финанс елына район бюджетында каралган акчалар чикләрендә, Балтач муниципаль районы бюджеты хисабына финансларга.

5. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авл хуҗалгы, оешма- предприятиеләре , учреждениеләре һәм муниципаль берәмлекләре (җирлекләре) арасында ТАССР ның 100 еллыгына һәм Балтач районының 90 ел тулуына багышланган район мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларын оештыруны Балтач районы Башкарма комитетына тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль район башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нотфуллин